ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

12.11.2014 г. Казань № 108

**Җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү турында**

2014 елның 30 декабрендәге “Күпфатирлы йортларны һәм башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” №214-ФЗ Федераль законны үтәп, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 28.3 статьясының 4 өлеше һәм, аларга карата 2007 елның 27 декабрендәге “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” №66-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган аерым муниципаль берәмлекләрдә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өлешендә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе турында нигезләмә (2007 елның 12 ноябрендә ТР МК №622 карары белән расл.) нигезендә,

**Б О Е Р Ы К  Б И Р Ә М:**

1. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 14.28 статьясында, 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне төзергә вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең Вазыйфаи затлар исемлеген расларга (Кушымта).

2. Исемлек нигезендә Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнарның таләпләрен бозуларның административ хокук бозу билгеләрен үз эченә алган очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясенең

Административ хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

3. Юридик бүлек башлыгына (Н.А.Курневич) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә һәм аны рәсми бастырып чыгаруга җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Инспекция башлыгының беренче урынбасары И.Н. Плюснинга йөкләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК Инспекциясенең
2014 елның “__” ___________
№_____ боерыгына кушымта

**Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 14.28 статьясында, 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне төзергә вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең Вазыйфаи затлар исемлеге**

1. Инспекциянең административ тәҗрибә һәм өлешләп төзүне контрольдә тоту бүлеге башлыгы.
2. Инспекциянең административ тәҗрибә һәм өлешләп төзүне контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчеләре, өлкән белгеч-юрисконсульты.